Ответы заданий муниципального этапа республиканской олимпиады школьников
по татарскому языку для русскоязычных учащихся
школ с обучением на русском языке
2025-26 учебный год, 4 класс

Рус мәктәпләрендә белем алучы рус телле укучылар өчен
татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәре җаваплары
2025-26 уку елы, 4 нче сыйныф

Максимальный (максималь) балл – 76

**1. Прочитайте слова и выделите, в которых есть звуки** (в каждой строчке по несколько слов). *(За каждое слово 0,5 б., максимальное количество – 3 балла)*

[гъ] – **гади,** герой, гепард, **багана**, **кыңгырау,** гөл.

[w] – вагон, **ватык, вак**, вариант, **тавык,** паровоз.

**2. Подчеркните слова, в которых количество букв не соответствует с количеством звуков** *(максимальное количество* – 3 *балла).*

Күлмәк, <u>яхшы</u>, укытучы, җәй, <u>таяк, кыяр</u>, матур, тәртипле.

**3. От данных существительных образуйте формы множественного числа.** *(Максимальное количество – 5 баллов)*

**Каен – каеннар**

**Каз – казлар**

**Көн – көннәр**

**Көзге – көзгеләр**

**Сәгать – сәгатьләр**

**4. Придумайте и напишите   прилагательные к слову КУЯН.**

*(Максимальное количество  – 8 баллов)*



АК, ЙОМШАК, КУРКАК, МАТУР, ҖИТЕЗ,  ШАЯН, ЗУР,  ЗУР КОЛАКЛЫ, КЫСКА КОЙРЫКЛЫ.

**5. Придумайте и напишите  глаголы** (*макс. количество   – 7 баллов).*

Мин иртән йокыдан ТОРДЫМ. Урынымны ҖЫЙДЫМ. Зарядка ЯСАДЫМ. Иртәнге аш АШАДЫМ. Тәрәзәдән урамга КАРАДЫМ. Урамда кар ЯУГАН. Ура! Чана, чаңгы  ШУАРБЫЗ!

**6. Прочитайте текст и ответьте на вопросы.** *Максимальное количество – 9баллов)*

Безнең песиебез бар. Аның исеме – Мыраубатыр. Аның үз урыны да бар. Мыраубатыр – бик матур песи. Аның алгы тәпиләре ак төстә. Ә муены аклы-каралы. Мыраубатыр тычканнарны тотарга бик ярата. Без дә аны бик яратабыз.

1. Назовите текст. *(1б.)* БЕЗНЕҢ ПЕСИ

2. Найдите имена собственные. *(1б.)* МЫРАУБАТЫР

3. Найдите слово, отвечающее на вопрос **кто?** *(1б.)* БЕЗ

4. Найдите синонимы к данным словам *(3 б.)*:

матур – *ЧИБӘР*

тәпиләре – *АЯКЛАРЫ*

песи – *МӘЧЕ*

5. Найдите антонимы к данным словам *(3б.)*:

матур – *ЯМЬСЕЗ*

арткы – *АЛГЫ*

бар – *ЮК*

**7. Запишите предложения в таком порядке, чтобы получился связный текст.** *(Максимальное количество – 7 баллов)*

| Җөмлә | Тәртип саны |
|---|---|
| Ул алманы кәгазьгә төрде дә мәктәпкә алып китте. | 4 |
| Бакчачы бабай Чулпанга бер алма бирде. | 1 |
| Тиздән күп итеп алмалар үсәр. | 7 |
| Алманың төшләрен мәктәп бакчасына утырттылар. | 6 |
| Ул алма бик зур иде. | 2 |
| Матур алманы Чулпан үзе генә ашарга кызганды. | 3 |
| Мәктәптә Чулпан алманы сыйныфташлары белән бүлешеп ашады. | 5 |

8**. Составьте предложения и запишите.** (*За каждый правильный ответ по два балла, максимальное количество – 6 баллов)*

1) бик, килде, кыш, соң, быел. БЫЕЛ КЫШ БИК СОҢ КИЛДЕ.

2) матур, нинди, туган, минем, җирем! НИНДИ МАТУР МИНЕМ ТУГАН ҖИРЕМ!

3) безгә, иртәгә, киләсезме, абыең, сез, белән, бергә? СЕЗ БЕЗГӘ ИРТӘГӘ АБЫЕҢ БЕЛӘН БЕРГӘ КИЛӘСЕЗМЕ?

**9. Спросите у друга на татарском языке.** *(Максимальное количество – 8 баллов)*

1) любит ли он читать книги

СИН КИТАП УКЫРГА ЯРАТАСЫҢМЫ?

2) будет ли участвовать на конкурсе

СИН БӘЙГЕДӘ (КОНКУРСТА) КАТНАШАСЫҢМЫ?

3) когда улетают птицы в теплые края

КОШЛАР КАЙЧАН ҖЫЛЫ ЯКЛАРГА КИТӘЛӘР?

4) есть ли у него интересная книга

СИНЕҢ КЫЗЫКЛЫ КИТАБЫҢ БАРМЫ?

**10. Напишите сообщение на тему “Кыш”.** *(10 предложений, максимальное количество – 20 баллов)*

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

Ответы заданий муниципального этапа республиканской олимпиады школьников
по татарскому языку для русскоязычных учащихся
школ с обучением на русском языке
2025-26 учебный год, 5 класс

Рус мәктәпләрендә белем алучы рус телле укучылар өчен
татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәре җаваплары
2025-26 уку елы, 5 нче сыйныф

Максимальный (максималь) балл – 90

1. **Сколько раз в стихотворении встречается звук [ө]?** *(Максимальное количество – 3 балла).*

Ләйлә

Урамнар бүген сөенгән,

Ап-ак кардан киенгән.

Ләйлә чанасын өстерәп

Чыгып китте өеннән. *(Һади Такташ)*

Ответ: 6 раз.

2. **Распределите слова по следующим категориям** *(максимальное количество – 6 баллов).*

Слова для выбора: сәгать, юлбарыс, көньяк, якты, бәйрәм, яшь.

Количество звуков и букв равны – БӘЙРӘМ, ЯШЬ, КӨНЬЯК

Количество букв больше количества звуков – СӘГАТЬ

Количество звуков больше количества букв – ЮЛБАРЫС, ЯКТЫ

3. **Замените фразеологизмы словом** *(максимальное количество – 4 балла)*

   Башы күккә тиде – ШАТЛАНДЫ

   Авызы ерылды – ЕЛМАЙДЫ

   Күз ачып йомганчы – БИК ТИЗ

   Күз салды – КАРАДЫ

4. **Напишите обобщенное название слов** *(максимальное количество – 6 баллов)*

Баян, курай, скрипка – МУЗЫКА УЕН КОРАЛЛАРЫ

Чуртан, сазан, алабуга – БАЛЫКЛАР

Чәкчәк, бәлеш, өчпочмак – ТАТАР ХАЛЫК АШЛАРЫ

Кыш, яз, җәй, көз – ЕЛ ФАСЫЛЛАРЫ

Көрәк, тырма, балта – ЭШ КОРАЛЛАРЫ

Кашкарый, энҗе, роза – ЧӘЧӘКЛӘР

**5. Соедините реплики с представителями профессии (***максимальное количество – 8 баллов).*

| | |
|---|---|
| 1) Сезнең товарларыгыз 2176 сум тора. | А) Пешекче |
| 2) Өчпочмакның эчлегенә бәрәңге, ит, суган, тоз, борыч кирәк. | Ә) Табиб |
| 3) Укучылар, өй эшләрен көндәлекләрегезгә язып куегыз. | Б) Китапханәче |

4) Сезгә бу даруларны эчәргә кирәк. В) Укытучы

5) Китап ун көнгә бирелә. Г) Сатучы

6) Итәкне тегеп бетердем. Д) Артист

7) Мин яңа спектакльнең репликаларын ятлыйм. Е) Тегүче

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Г | А | В | Ә | Б | Е | Д |

**6. Подберите подходящие по смыслу слова, например, *тирән – тирән күл***
*(максимальное количество – 7 баллов)*

җылы БИЯЛӘЙ
салкын КЫШ
йомшак МЕНДӘР

тылсымлы ТАЯК

озын ТАЯК

биек ЙОРТ

моңсу ҖЫР

**7. Продолжите предложения** *(максимальное количество – 6 баллов).*

1) Мин кышны бик яратам, чөнки ДУСЛАРЫМ БЕЛӘН КЫШКЫ УЕННАР УЙНЫЙБЫЗ.

2) Саф һавада йөрү бик файдалы, шуңа күрә КӨН ДӘ УРАМГА ЧЫГАРГА КИРӘК.

**8. Напишите вопросы к данным ответам (***максимальное количество – 15 баллов).*

1) СИН НИЧӘНЧЕ СЫЙНЫФТА УКЫЙСЫҢ?
Мин бишенче сыйныфта укыйм.

2) СИН ТАТАР ТЕЛЕНДӘ СӨЙЛӘШӘ БЕЛӘСЕҢМЕ?
Әйе, мин татар телендә сөйләшә беләм.

3) СИҢА НИНДИ ДӘРЕСЛӘР ОШЫЙ?
Миңа әдәбият дәресләре ошый.

4) "ТУГАН ТЕЛ" ШИГЫРЕН КЕМ ЯЗГАН?
"Туган тел" шигырен Габдулла Тукай язган.

5) СИНЕҢ ЭНЕҢ МУЗЫКА МӘКТӘБЕНДӘ УКЫЙМЫ?

Юк, минем энем музыка мәктәбендә укымый.

**9. Добавьте возможные слова в нераспрастраненное предложение**
*(максимальное количество* – 5 *баллов)*

Мин КИЧӘ ГАИЛӘ БЕЛӘН КЫЗЫКЛЫ МУЛЬТФИЛЬМ карадым.

**10. Прочитайте сказку. С каким вариантом утверждения вы согласны?**
*(Максимальное количество* – 7 *баллов)*

Төлке белән Каз

*(Татар халык әкияте)*

Бервакыт Төлке Казны тотып алган да:

— Каз, мин сине ашыйм! — дигән.

Каз боегып (күңелсезләнеп) калган.

— Мин риза, Төлке. Тик син миңа бер биеп калырга рөхсәт ит, — дигән Каз.

— Әйдә, бие, — дигән Төлке. — Ашарга өлгерермен әле.

Каз, канатларын җилпеп, бер урында тыпырдый башлаган. Төлке:

— Әй оста биисең, Каз! — дип көлә икән.

Ә Каз, канатларын җилпеп, бер урында торган-торган да очып киткән. Төлке авызын ачып калган.

| | | |
|---|---|---|
| Каз куркып еларга тотынган. | Әйе | **Юк** |
| Төлке ач калган. | **Әйе** | Юк |
| Каз оча белми. | Әйе | **Юк** |
| Каз җырлаган. | Әйе | **Юк** |
| Каз төлкедән кача алмаган. | Әйе | **Юк** |
| Каз төлкедән дә хәйләкәррәк булып чыккан. | **Әйе** | Юк |
| Әкият тапкырлык турында. | **Әйе** | Юк |

**11. Из данных слов составьте и запишите пословицу.** (*Максимальное количество –* 3 *балла).*

бар, эшнең, вакыты, үз, һәрбер

*ҺӘРБЕР ЭШНЕҢ ҮЗ ВАКЫТЫ БАР.*

**12. Озаглавьте и опишите рисунок** *(10 предложений, максимальное количество – 2**0 баллов).***



**Рус телендә урта гомуми белем бирү мәктәбенең рус төркемендә укучылар өчен татар теленнән үткәрелә торган муниципаль туры олимпиада биремнәренең җаваплары**
**2025/2026 уку елы, 6 нчы сыйныф**
***(Максимальное количество баллов – 93)***

1. **Придумайте название рисунку и составьте 3 вопроса**

**(*максимальный балл – 12)***

**2. Прочитайте стихотворение и напишите какое слово пропущено. *(максимальный балл – 3)*.**

*Кар*

**3. Заполните таблицу *(максимальный балл – 12)***.

| | + | – | ? |
|---|---|---|---|
| *мин* | ***барам*** | *бармыйм* | *бараммы* |
| *син* | ***барасың*** | ***бармыйсың*** | ***барасыңмы*** |
| ***ул*** | *бара* | ***бармый*** | *барамы* |
| *без* | ***барабыз*** | *бармыйбыз* | ***барабызмы*** |
| *сез* | ***барасыз*** | ***бармыйсыз*** | *барасызмы* |
| ***алар*** | *баралар* | *бармыйлар* | ***баралармы*** |

**4. Спросите у своего друга по-татарски (максимальный балл – 5).**

*1) Син иртәнге ашка нәрсә яратасың?/ Син иртән нәрсә ашарга яратасың?*

*2) Син матур киенергә яратасыңмы?*

*3) Синең яраткан бәйрәмең нинди? / Син нинди бәйрәм яратасың?*

*4) Син күбрәк татлы яратасыңмы әллә тозлымы?*

*5) Синең йорт хайваның бармы?*

**5. Переведите предложения *(максимальный балл – 14)*.**

*1) Бүген кояшлы.*

*2) Ул әкрен бара./ Ул әкрен йөри.*

*3) Аңа күп уйларга кирәк түгел.*

*4) Еракта таулар күренә.*

*5) Без пәнҗешәмбе кич белән/кичен нишлибез/нишләячәкбез?*

*6) Ул "Бию" номинациясендә җиңеп чыкты. / Ул "Бию" номинациясендә җиңде.*

*7) Бик күңелле булды!*

**6. Допишите окончания в предложениях (максимальный балл – 11).**

*1) Безнең табигат**<u>ебез</u>** бик матур һәм бай.*

*2) Чиста һава кеше**<u>ләргә</u>** дә, хайван**<u>нарга</u>** да кирәк.*

*3) Казан шәһәр**<u>е</u>** уртасында Кабан күл**<u>е</u>** бар.*

*4) Агач**<u>ларның</u>** яфрак**<u>лары</u>** сары төс**<u>тә</u>**, үләннәр корыган.*

*5) Дендрарий**<u>да</u>** дөнья**<u>ның</u>** төрле ил**<u>ләреннән</u>** китерелгән үсемлекләр бар.*

**7. Напишите время цифрами *(максимальный балл – 5)*.**

*1) 21.00*

*2) 10.30*

*3) 06.45*

*4) 07.10*

*5) 07.00*

**8. Предложения разбиты на части. Поставьте слова в правильном порядке и запишите (максимальный балл – 10).**

*1) Мин кичә курчак театрында спектакль карадым.*

*2) Былтыр дустым Анталия шәһәрендә ял итте.*

*3) Бу дәреслекне без китап кибетендә күрдек.*

*4) Көзен кошлар җылы якларга очалар.*

*5) Җирдә иң зур байлык – су.*

**9. Перевидите названия профессий *(максимальный балл – 6)*.**

*Повар – **пешекче**, ученый – **галим**, летчик– **очучы**, рабочий – **эшче**,*

*швея – **тегүче**, певица – **җырчы**.*

**10. Напишите о лучшем подарке, который тебе когда-либо дарили (за каждое верное предложение – 3 балла, максимальное количество баллов – 15).**

**Рус телендә урта гомуми белем бирү мәктәбенең рус төркемендә укучылар өчен татар теленнән үткәрелә торган муниципаль тур олимпиада биремнәренең җаваплары**
**2025/2026 уку елы, 7 нчы сыйныф**

***(Максимальное количество баллов – 90)***

**1. Предложения разбиты на части. Поставьте слова в правильном порядке и запишите** *(максимальный балл – 6).*

*1) Күренекле композитор Нәҗип Җиһанов Казахстанның Җаек шәһәрендә туа.*

*2) Ул биш яшеннән ятим кала.*

*3) Нәҗип Җаектагы балалар йортында тәрбияләнә.*

*4) Ул Казанда яшәүче апасы янына яшәргә килә.*

*5) Апасында үзлегеннән фортепианода уйнарга өйрәнә.*

*6) Яшь композитор Казанда Муса Җәлил белән таныша.*

**2. Прочитайте текст и напишите ответ**

*(максимальный балл – 3).*

***<u>Безнең гаилә</u>***

**3. Напишите советы к представленным ситуациям** *(максимальный балл – 10).*

*1) Мин иртән ашарга яратмыйм./ Иртән җиңелчә ризыклар ашап кара.*

*2) Минем дусларым аз. / Кешеләргә игьтибарлы бул.*

*3) Өй эшләрен озак эшлим./ Таймер белән эшләргә өйрән.*

*4) Көннәр салкын һәм карсыз./ Җылы киенеп йөр.*

*5) Иртәгә мәктәптә ярыш була. / Син дә катнаш.*

**4. Переводите предложения** *(максимальный балл – 12).*

*1) Дустым сәнгать белән кызыксына.*

*2) Дәрес сәгать бердә бетте.*

*3) Нинди матур күлмәк!*

*4) Сиңа табибка барырга кирәк.*

*5) Мин бик иртә тордым.*

*6) Әйдәгез танышабыз.*

**5. Придумайте вопросы к представленным ответам** *(максимальный балл – 12).*

*1. – Син быел нинди түгәрәккә язылдың?*

*– Мин быел җыр түгәрәгенә язылдым.*

*2. – Син биергә яратасыңмы?*

*– Әйе, мин биергә яратам.*

*3. – Программалаштыру түгәрәгенә язылмыйсыңмы?*

*– Юк, миңа программалаштыру кызык түгел.*

*4. – Сиңа спорт секциясе ошыймы?*

*– Әйе, ошый. Без күп шөгыльләнәбез.*

*5. – Син быел нинди олимпиадага барасың?*

*– Быел мин төрек теле буенча олимпиадага барам.*

*6. – Син волонтер һөнәре белән танышмы?*

*– Әйе. Минем дустым волонтер булып эшли.*

**6. Заполните таблицу *(максимальный балл – 12)*.**

| | + | – | ? |
|---|---|---|---|
| *мин* | *катнаштым* | ***катнашмадым*** | *катнаштыммы* |
| *син* | ***катнаштың*** | *катнашмадың* | ***катнаштыңмы*** |
| ***ул*** | *катнашты* | ***катнашмады*** | ***катнаштымы*** |
| *без* | ***катнаштык*** | *катнашмадык* | ***катнаштыкмы*** |
| ***сез*** | ***катнаштыгыз*** | ***катнашмадыгыз*** | *катнаштыгызмы* |
| *алар* | *катнаштылар* | ***катнашмадылар*** | *катнаштылармы* |

**7. Найдите в таблице слова (слова спрятаны по вертикали и горизонтали) и обведите или закрасьте их. (*за каждый верный ответ 1 балл, макс. - 20)*.**

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Б | С | Ә | Б | Ү | Р | Е | К | А | Р |
| Ү | Т | Җ | О | К | А | П | Ч | Ы | К |
| Л | И | И | З | Б | Ү | Р | Е | К | Ш |
| Ә | М | Л | Л | П | Ч | А | Ң | Г | Ы |
| К | Е | С | А | Л | К | Ы | Н | В | Ч |
| Й | Р | Җ | В | А | К | Н | Я | А | А |
| Я | А | Ч | Ы | Р | Ш | Ы | Ң | О | Н |
| К | Я | И | К | Б | Ә | С | А | Ө | А |
| О | К | Р | У | Ч | К | Ө | Р | Т | Һ |
| Ш | У | Г | А | Л | А | К | К | Ы | З |

**8. Напишите 5 предложений о своем любимым учителе (за каждое верное предложение – 3, максимальный балл – 15).**

**Рус телендә урта гомуми белем бирү мәктәбенең рус төркемендә укучылар өчен татар теленнән үткәрелә торган муниципаль тур олимпиада биремнәре җаваплары**
**2025-2026 уку елы, 8 нче сыйныф**

**Максималь балл – 93**

**1. Озаглавьте картину. Составьте 5 вопросительных предложений по картине. (12 баллов, по 2 балла за каждый правильный ответ).**

**Ачкыч:** Китап ярат учылар клубы. Бу картинада кемнәр сурәтләнгән? Укучылар нинди китаплар укыйлар? Укучылар кайда утыралар? Һ.б.

| 2 (1 балл) | 3 (1 балл) | 4 (1 балл) | 5 (1 балл) | 6 (5 балл) | 7 (1 балл) | 8 (4 балл) |
|---|---|---|---|---|---|---|
| г | б | а | б | җитте<br>алып килде<br>капланды<br>башланды<br>күренде | в | 2 |

**9. Прочитайте текст, по содержанию текста в таблице ставьте “+” или “-”. (18 баллов)**

| № | Җөмләләр | Әйе | Юк |
|---|---|---|---|
| 1. | Декабрь - кышның беренче ае. | + | |
| 2. | Җир - ап-ак кар белән, агачлар көмеш бәс белән капланган. | + | |
| 3. | Һава чиста һәм салкын, һәр аваз еракка китеп тарала. | | + |
| 4. | Кояш югары күтәрелә. | | + |
| 5. | Кояшның аксыл яктысы кар өстендә зәңгәр күләгәләр ясый. | + | |
| 6. | Көндез тыныч, кар авырлыгы астында ботаклар сына. | | + |
| 7. | Кич бик соң җитә. | | + |
| 8. | Күк тиз караңгылана, йолдызлар кабына. | + | |
| 9. | Өйләрнең тәрәзәләрендә сары утлар җемелди. | | + |

**10. Допишите окончания слов в предложениях. (13 баллов)**

| № | Предложения | Баллы (макс.) 13) | Сумма (фактич.) ( ) |
|---|---|---|---|

| | | | |
|---|---|---|---|
| **1.** | Декабрь – ел**ның** соңгы ае, ул могҗизалар**га** бай. | 2 | |
| **3.** | Декабрь атама**сы** латинча decem («ун») сүзе**ннән** килеп чыга. | 2 | |
| **4.** | Борынгы грек календаре**нда** декабрь унынчы ай булган, чөнки ел март**тан** башланган. | 2 | |
| **5.** | Шәһәр әкренләп бәйрәм**гә** әзерләнә: тәрәзәләр**дә** гирляндалар кабына, мәйданнар**да** чыршылар басып тора. | 3 | |
| **6.** | Һава**да** мандарин һәм ылыс исе аңкый. | 1 | |
| **7.** | Декабрь**дә** без һәр кар бөртег**ен** күреп калырга һәм үз йөрәгебез**гә** колак салырга тырышабыз. | 3 | |

**11. Используя содержание текста 9-го задания, составьте диалог из 10 реплик. (20 баллов, по 2 балла за каждую правильную реплику)**

**Ачкыч:**

- Дустым, декабрь нинди ай?
- Декабрь - елның соңгы ае.
- Декабрь сүзе нәрсәне аңлата?
- Аның исеме латин decem («ун») сүзеннән килеп чыккан.
- Декабрьдә һава торышы нинди?
- Җир ап-ак кар белән капланган. Һава чиста һәм салкын.
- Декабрьдә шәһәрләрдә яңа елга ничек әзерләнәләр?
- Тәрәзәләрдә гирляндалар кабына, мәйданнарда чыршылар басып тора, ә һавада мандарин һәм ылыс исе аңкый.
- Декабрьдә син нәрсә көтәсең?
- Мин могҗиза, яңа очрашулар көтәм.

**12. Напишите краткое сочинение-рассуждение о пользе чтения художественной литературы. (8 предложений - 16 баллов)**

**Ачкыч:**

Китап уку һәркемгә файдалы. Китап укыганда без геройларны, вакыйгаларны, табигать күренешләрен күз алдына китерәбез. Китаплар сүз байлыгын арттыра - без яңа сүзләрне истә калдырабыз, катлаулы җөмләләр төзергә өйрәнәбез. Әдәби әсәрләр кешеләрне яхшырак аңларга ярдәм итә. Моннан тыш, уку хәтерне һәм игътибарны арттыра. Китаплар белемнәрне киңәйтә: без төрле чорлар, мәдәниятләр һәм тарихи вакыйгалар турында

беләбез. Уку - ял итү һәм стресстан чыгу өчен менә дигән мөмкинлек: кызыклы сюжет көндәлек тормыштан читкә китеп торырга ярдәм итә.

**Рус телендә урта гомуми белем бирү мәктәбенең рус төркемендә укучылар өчен татар теленнән үткәрелә торган муниципаль тур олимпиада биремнәре җаваплары 2025-2026 уку елы, 9 нчы сыйныф**

**Максималь балл - 102**

**1. Озаглавьте картину. Составьте 5 вопросительных предложений по картине. (12 баллов, по 2 балла за каждый правильный ответ)**

Китап тоткан кыз.

Картинада нәрсә тасвирланган? Кыз нинди китап укый? Бу кызга ничә яшь? һ.б.

**2. Задания по тексту.**

1) Татарлар **Россиянең** һәм дөньяның төрки телле иң күпсанлы халыкларының берсе. Аларның тарихы Идел Болгары дәүләтенә барып тоташа. Татарларның **мәдәнияте** дөньякүләм танылу алган. Аның бәйрәмнәре, ашлары һәм сәнгате бик төрле.

2) Бүген татарлар сан буенча Россия Федерациясендә **икенче** урында торалар. Аларның төп һәм **тарихи** ватаны - Татарстан Республикасы, аның **башкаласы** – Казан шәһәре. Татарлар **зур** илнең Мәскәүдән алып Ерак Көнчыгышка кадәрге барлык **төбәкләрендә** диярлек **яшиләр**.

3) Татар халкы**ның** яшәү география**се** Россия белән генә чикләнми. Күп санлы һәм берләшкән диаспора бөтен Җир шары**нда** таралган. Татарлар Урта Азия, Төркия, Финляндия, Германия, АКШ һәм Кытай илләре**ндә** яши. Хәтта мең километр ераклык**та** да алар үз телләр**ен**, гореф-гадәтләр**ен** һәм мәдәни истәлекләр**ен** кадерләп саклыйлар.

4) **Сабантуй - борынгы татар бәйрәме. Ул язгы кыр эшләренең тәмамлануын белдерә. Бәйрәмдә спорт ярышлары үткәрелә. Төп ярышлар - көрәш һәм ат чабышы. Бәйрәмдә һәрвакыт халык музыкасы һәм биюләре күп була. Кунакларны милли ризыклар белән сыйлыйлар. Сабантуй хезмәт шатлыгын һәм мул уңышка өметне гәүдәләндерә. Бу бәйрәмне бик яраталар һәм кадерләп саклыйлар.**

5) Хәзерге татарлар гасырлар дәвамында яшәп килгән традицияләрне саклыйлар. Алар халыкара дәрәҗәдә фәнгә, бизнеска, мәдәнияткә һәм спортка зур өлеш кертәләр. Дөньяда танылган татарлар күп. Минем шуларның берсе турында язасым килә...

**А) Озаглавьте текст. (2 балла)**

________________________________________________________

**Б) Разделите текст на микротемы (составьте план). (10 баллов, по 2 балла за каждый правильный ответ)**

_________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________

**В) С первого абзаца текста выпишите слова, в которых количество букв и звуков не совпадают. (2 балла)**

**Г) Во втором абзаце текста дополните предложения недостающими словами. (12 баллов, по 2 балла за каждое правильное предложение)**

**Д) Допишите пропущенные окончания слов в предложениях третьего абзаца (16 баллов, по 2 балла за каждый правильный ответ)**

**Е) Переведите четвертый абзац на татарский язык. (16 баллов, по 2 балла за каждое правильное предложение)**

**Ж) Продолжите содержание пятого абзаца и напишите краткий рассказ об одном всемирно знаменитом татарине (например, о деятеле науки, культуры или спорта) - 8 предложений (16 баллов, по 2 балла за каждое правильное предложение)**

Ул — Ренат Акчурин исемле галим. Ул йөрәк хирургиясе өлкәсендә дөньякүләм танылу алган. Аның эшләгән операцияләре меңнәрчә кешене коткарды. Акчуринның фәнни хезмәтләре бик күп. Ул татар телен, мәдәниятен онытмады. Ул чит илләрдә лекцияләр укыды, үзен татар дип танытты. Һ.б.

**3. Составьте диалог из 8 реплик по ситуации: Два друга обсуждают, как провести зимние каникулы. Один считает, что читать книги — скучно и бесполезно, лучше играть в видеоигры или смотреть сериалы. Другой — страстный книголюб и пытается убедить друга, что чтение может быть увлекательным и полезным. (16 баллов)**

- Дустым, озакламый каникуллар җитә. Син аны ничек үткәрергә уйлыйсың?

- Кышкы каникулларда компьютер уеннары уйнарга, сериаллар карарга телим! Ә син?

- Ә мин китаплар укырга телим.

- Китап уку бик күңелсез бит?

- Мин риза түгел! Китап уку һәркемгә файдалы. Китап укыганда без геройларны, вакыйгаларны күз алдына китерәбез.

- Компьютер уеннары вакытында адреналин барлыкка килә.

- Китап укыганда да адреналин бар. Мәсәлән фантастик яки детектив әсәрләр укыганда.

- Ярар, мин дә укырмын... Кызык булмаса, ташлыйм.

- Килештек! Китап уку сиңа ошар дип ышанам.

**Рус мәктәпләрендә белем алучы рус телле укучылар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәренең җаваплары**
**2025-26 уку елы, 10 сыйныф**

Максимальный (максималь) балл – 90

1.

1) **Портреты каких известных личностей татарского народа Вы узнали? Напишите. (3 б.).**
2) **Напишите 5-6 предложений, характеризующие деятельность одного из них (**по **3** балла за каждое правильное предложение, макс. б. – **18**).



1) Габдулла Тукай – шагыйрь.

Салих Сәйдәшев - композитор.

Минтимер Шәймиев – Татарстан Республикасының беренче президенты.

2) Салих Сәйдәшев татар халкының танылган, талантлы композиторы. Музыкага сәләте балачактан ук ачылган. Ул озак еллар татар театрында дирежер булып эшләгән. Күп кенә спектакльләргә көйләр язган. Алар Кәрим Тинчурин белән тыгыз иҗади хезмәттәшлектә торганнар. С.Сәйдәшевнең Совет Армиясе маршы бөтен илгә танылган.

**2. Найдите правильный перевод предложения** : ***"Бөтен ышанычым  сездә*** **(1 б.).**

1) **Вся надежда на вас.**
2) Вся наша надежда.
3) Я на вас надеюсь.
4) Я навеки ваш.

**3. Калын хәрефләр белән бирелгән фигыльнең төрен билгеләгез (1 б.).**

*Ленар микрофон янына* ***килеп*** *рәхмәт әйтә башлады.*

1) сыйфат фигыль
2) **хәл фигыль**
3) исем фигыль
4) инфинитив

**4. В какой последовательности необходимо поставить выражения, чтобы получилось предложение? (1 б.)**

А) вакытында аша

Ә) җимешне

Б) вакытында эшлә

В) эшне

**В, Б, Ә,А**

**5. Прочитайте текст и переведите на русский язык  (по2 б., макс.б. 14).**

Что же это такое искусственный интеллект?

Если сказать просто, Искусственный интеллект это умение компьютера принимать самостоятельные решения, как человек. В последние годы это направление шагнуло далеко. Специалисты начали делать для использования в разных областях  программы и приложения. Самые успешные из них относятся к области искусства. Например,  недавно появилось приложение умеющие изменить автопортреты в разные стили. И не только это, появилась сеть рисующий по содержанию текста.

6. **Допишите продожение пословиц (по 2 б., макс. б. - 6).**

Дөньда иң кечкенә бәхет – байлык, иң зур бәхет - СӘЛАМӘТЛЕК .

Сәламәтлекне сатып АЛЫП БУЛМЫЙ.

**7. Выполните коммуникативные задания (по 2 балла за каждый правильный ответ, макс. б. -10).**

Скажи родителям (маме , папе):

- что ты беспокоишься за их здоровье;
- МИН СЕЗНЕҢ СӘЛАМӘТЛЕГЕГЕЗ ӨЧЕН БОРЧЫЛАМ.

______________________________________________________________

- что им необходимо ехать отдыхать;
- СЕЗГӘ ЯЛГА БАРЫРГА КИРӘК.

______________________________________________________________

- что очень полезно употреблять витаминные продукты;

- ВИТАМИНЛЫ РИЗЫКЛАР КУЛЛАНУ БИК ФАЙДАЛЫ .________________________________________________________

- что перед сном нужно гулять на свежем воздухе;

- ЙОКЛАР АЛДЫННАН САФ ҺАВАДА ЙӨРЕРГӘ КИРӘК.

- что ты очень благодарен (на) им и очень хочешь, чтобы они были здоровые;

- МИН СЕЗГӘ БИК РӘХМӘТЛЕ ҺӘМ СЕЗНЕҢ СӘЛАМӘТ БУЛУЫГЫЗНЫ ТЕЛИМ.

8. **В какой последовательности нужно расставить предложения, чтобы получился текст? (Макс. б. – 4).**

А) Соңгы елларда умартачылык продуктларының дәвалау үзенчәлекләре фәнни нигездә өйрәнелә.
Ә) Ашамлык буларак та бал бик файдалы.
Б) Бал составында алтмышка якын матдә барлыгы ачыкланды.
В) Бал борынгы заманнарда ук дәвалау максатында файдаланылган.

1) Б, Ә, А, В **2) В,А, Б, Ә** 3) Ә, А, В, Б 4) Ә, В, А, Б

**9. Допишите пропущенные окончания ( по 1 б., макс. б.- 12).**

1) Табигатьне саклАУ өчен пластик кулланМАСКА , аның урынына биотукыма кулланЫРГА кирәк.
2) МарсТА су бар, ләкин кешеЛӘР өчен яраклы һава юк. Ул колонияләштерҮ өчен иң якын планета.
3) Фрилансерлар читТӘН торЫП эшлиләр. Алар төрле чит илЛӘРДӘ сәяхәт итӘ алалар, эшКӘ алучыларДАН мөмкин кадәр бәйсез.

**10. Прочитайте текст. Как вы думаете, какой был ответ Сократа, изложите в 9-10 предложениях (по 2 балла за каждое правильно составленное предложение, макс. б -20).**

- Ә син бу турыда ни уйлыйсың?

Сократ әйтте:

-

**Рус мәктәпләрендә белем алучы рус телле укучылар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәренең җаваплары**
**2025-26 уку елы, 11 сыйныф**

Время проведения (үткәрү вакыты) – 180 минут

Максимальный (максималь) балл – 97 балл

**1.Озаглавьте картину (2 б.).** *ХӨКЕМ АЛДЫННАН; БАШ ИМӘС МУСА ҖӘЛИЛ ... (рәссам биргән атама булмаса да мөмкин, темадан чыгып бирелсен)*
**Составьте 5 вопросительных предложений по картине (по 3 балла за каждое предложение, макс. б. – 15+2=17 б.**).



1. *Рәссам шагыйрь образының  нинди сыйфатларын чагылдыра алган?*
2. *Муса Җәлил нинди халәттә?*
3. *Сорау алучыларның халәтләре нинди?*
4. *Муса Җәлилнең сынмас рухы нинди штрихларда чагылыш тапкан?*
5. *Әлеге картина күңелегездә нинди тойгыларны уятты?* .....

2.**К словосочетаниям присоединяйте окончания  и с ними составьте предложения** (За каждое правильное словосочетание и правильно составленное предложение по 2 балла (1+1), **макс. б. – 6).**

| **Нәрсәне?** | **Кая?** | **Кайда?** |
|---|---|---|
| Сөембикә манарасыН | Сөембикә манарасыНА | Сөембикә манарасыНДА |

*Сөембикә манарасын төрле яклап фотога төшердем. Туристлар Сөембикә манарасына менәргә теләкләре булуын әйттеләр. Сөембикә манарасында ярым ай бар*

---

**3. Среди слов, приведенных в скобках, найдите правильный вариант и подчеркните** (по 2 б, макс. -10) .

1). Урмандагы алан (кебек, **буйлап**, дип) Керпе бара. 2). Кая (**карама**, күрмә, тыңлама), кыштырдавык яфраклар. 3). Аяк асты, бөтен тирә-як сары, кызгылт (агачлар, ботаклар, **яфраклар**) белән түшәлгән. 4) Калын итеп түшәлгән яфрак (**келәм**, идән, җир) өстеннән баруы кызык та, рәхәт тә. 5). (Язның, җәйнең, **көзнең**) шушындый җылы, вак яңгыр сибәләп торган вакытын ярата Керпе. (Ф.Сафиннан)

4. **Выберите и вместо многоточия  ставьте фразеологизм.** ( по 2 б., макс. б. -8)

А. Бу мәсьәләгә **(4)** ярамый.

Ә. Узган ел **(3)** вакыйгаларга бай булды.

Б. Әнием аш-су пешерергә бик оста, аның бәлешләре **(1)** була.

В. Кешедән **(2)** җиңел, аңа ярдәм итергә тырышырга кирәк.

1) телеңне йотарга
2) йөз чөерергә
3) уңышлардан  баш әйләнергә
4) күз йомарга

5**. Найдите слова, спрятанные в следующих словах (макс.-10 б.).**

умыртка, юмартлык

*умыртка*: ***ук, ука, урт, урак, урам, утар, март, кыр...***

*юмартлык****:март,  арт, юл, тар, лар, ю, карт....***

**6. Прочитайте, напишите ответ (макс. – 5 б.)**

Роза, Нина, Наза, Әсма бер малай белән танышалар. Үзләренең исемнәрен әйтәләр дә:

- Синең исемең ничек соң? – дип сорыйлар.
- Берегезнең исеменнән беренче  хәрефне, икенчегезнең исеменнән икенче хәрефне, өченчегезнең исеменнән өченче хәрефне, дүртенчегезнең исеменнән дүртенче хәрефне алып, бергә тезгәч, минем исемем килеп чыга, - дигән малай.

Малайның исеме ничек булган?

***Риза***

**7. Выберите правильный вариант (макс. б. -5)**

Проблемалар килеп чыкса, якын кешеләрең белән ***киңәшләшергә****/ көлешергә/елашырга* кирәк.

Кешеләргә уңай хисләр *кирәкми/булмый/****ярдәм итә****.*

Тискәре эмоцияләрне *булдыр/онытма/****уңайлары белән алмаштыра бел****.*

Начар кәеф булса*, ела/кычкыр/****сәбәбен аңларга тырыш.***

Сәламәтлекне какшатуга сәбәп була торган эмоцияләрне *кичер/сакла/***контрольдә тот***.*

**8. Переведите на русский язык** (за каждую фразу по 1б., макс. 5 б.).

1. Мин синең белән тулысынча килешәм.
2. Һичшиксез! Әлбәттә!
3. Мин катгый рәвештә каршы.
4. Булмас!
5. Менә сиңа мә!

______________________________________________________________

1. *Я полностью с тобой соглашаюсь*
2. *Несомненно! Конечно!*
3. *Я категорический против*
4. *Не может быть!*
5. *Вот тебе на!*

______________________________________________________________

**9. Составь предложения, раставив слова, выражения правильно (по 1 б., макс.б -5)**

1. *Кечкенә шәһәрләрдә, авылларда гореф-гадәтләр яхшы саклана.*
2. *Кечкенә шәһәрләрнең, авылларның тарихы күп елларга сузыла.*
3. *Һәр шәһәрчекнең, авылның үзенә генә хас үзенчәлеге бар.*
4. *Кечкенә шәһәрдә, авылда кешеләр бер-берсен белән дус яши.*
5. *Кечкенә шәһәрдән матур табигать тә ерак түгел.*

1. гореф-гадәтләр/саклана/авылларда/яхшы/ кечкенә шәһәрләрдә/
2. авылларның / тарихы/сузыла/кечкенә шәһәрләрнең/күп елларга
3. үзенчәлеге бар/авылның/Һәр шәһәрчекнең/үзенә генә хас/
4. бер-берсен белән/кечкенә шәһәрдә/дус яши/авылда/кешеләр/
5. табигать тә/матур /кечкенә шәһәрдән/ерак түгел

**10. Прочитайте текст и выполните задания по тексту (макс.б. -26)**

Туган илне сагыну дигән хис тә төрле дәрәҗәдә, төрлечә була икән. Менә син чит ил урамнарында ялгыз йөреп кара. Шагыйрь әйтмешли, син кем кадерлесе анда? Кинәт авырдың, ди. Докторга күренү өчен, күпме доллар кирәк? Синең өчен анда беркем дә җавап бирми, син анда берәүгә дә кирәк түгел. Чит дөньяның иң эре башкаласында, иң зур урамның уртасында син – ком бөртеге. Ватан дигән газиз җирне әнә шунда син бөтен нечкәлеге белән аңлый башлыйсың. Мин бу хисне күп тапкырлар дөньяның күп калаларында кичердем. Бу хис Римда, Тегеранда, Каһирәдә, Истанбулда, Коломбода,

гомумән, бер җирдә дә минем күңелемнән китмәде. Чын сагыну үзен шунда танытты.

Безнең авылда яшьлеген Уральск шәһәрендә уздырган тегүче Гатият абзый бар иде. Ул заманында Тукайлар, Кариевләр белән таныш булган. Шул абзый сөйли торган иде: “Чит җирләрдә шунысы читен: үз авылыңның су буендагы ташына кадәр сагынасың”. Без, малайлар, аннан көлә идек. Су буендагы чыпчык ташын кем сагынсын? Ләкин без ашыгыбрак көлгәнбез. Гатият абзыйның бу сүзләрен мин хәзер яхшы аңлыйм.

Һәркемнең үз балачагы, үз шәһәре, үз авылы, үз чишмәләре, үз таулары бар. Һәркем дөньяда безнең шәһәрдән, авылдан, чишмәдән, таудан да матур урын юк дип ышанып яши бирә.Җир шарында алты кыйтга бар һәм алар һәрберсе үзенчә матур. Әмма иң матуры, әлбәттә, син туган, син үскән җир.

(*М.Мәһдиев*)

**1) Придумайте название текста (4 б.)**

*Чын сагыну хисе*

**2) Назовите смысловые абзацы текста (по 2 б., макс. б. - 6).**

*1). Читтә йөргәндә туган илеңне сагыну хисе.*

*2). Гатият абзый күңелендәге сагыну хисе.*

3*). Үзеңнеке иң матуры.*

3) **Изложите в 6 - 8 предложениях суть отрывка из текста.**

Һәркемнең үз балачагы, үз шәһәре, үз авылы, үз чишмәләре, үз таулары бар. ...

(по 2 б., макс. б. – 16)

________________________________________________________________

________________________________________________________________

________________________________________________________________

________________________________________________________________

________________________________________________________________

________________________________________________________________

________________________________________________________________

________________________________________